СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 270 от 27.06.2024

На № __________ от _____________

# КАРАР

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә» 2018 елның 09 апрелендәге 208 номерлы Саба муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләренең урынбасарларының, аудиторларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә» 2018 елның 09 апрелендәге 208 номерлы Саба муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме билгеченең 13 323 сум күләмендә вазыйфаи хезмәт хакы расլансын.»;

**1.2.** Карарның 1 нче кушымтасын яңа редакциядә әлеге карарның 1 нче кушымтасына ярашлы итеп язырга.

**2.** «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 09 апрелендәге 208 номерлы Саба муниципаль

районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә» карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.5.3 пунктында «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 3.5.4 пунктында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләре белән алыштырырга;
- 6.1 пунктының 5 пунктчасында «18 процент» сүзен «41 процент» сүзләре белән алыштырырга;

**3.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2024 елның 1 июленнән штат расписаниеләрен үзгәртергә.

**4.** Әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла.

**5.** Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

**6.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru.

Саба муниципаль районы
Башлыгы Р.Н. Минниханов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
2024 елның 27 июенендәге 270
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасарының, җирле үзидарәнең Саба муниципаль районында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы контроль-хисап палатасы Рәисенең акчалата бүләкләү күләмнәре**

| Вазифаларның атамалары | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 35 272 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 31 745 |
| Депутатлар | 17 297 |
| Сайланган җирле үзидарә органнары әгъзалары | 14 697 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисе | 31 745 |